| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 декабрь, 2025 ел Алабуга шәһәре № 29

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кабат конкурс үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 24 статьясы, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы, Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 221 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үтмәгән дип тану турындагы 2025 елның 10 декабрендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кабат конкурс үткәрергә (алга таба - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе).

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс өчен кандидатлардан документлар кабул итү 2025 елның 26 декабреннән 2026 елның 15 гыйнварына кадәр, 423603, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт, 16 нчы кабинет адресы буенча, көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш кабул ителә.

3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү датасын 2026 елның 21 гыйнварына, конкурс үткәрү вакытын – 10 сәгать 00 минутка, конкурсны үткәрү урыны итеп Алабуга

муниципаль районы Советы бинасын (Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт) билгеләргә.

4. Конкурсны Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2012 елның 20 апрелендәге 221 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Татарстан Республикасы Раисының 2025 елның 4 сентябрендәге 708 номерлы Указы белән расланган комиссия составында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2025 елгың 15 октябрендәге 9 номерлы карары (11.11.2025 ел, №17 карары редакциясендә) һәм Алабуга шәһәр Советының 2025 елгың 11 ноябрендәге 11 номерлы карары нигезендә үткәрергә.

5. Әлеге карарны һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы хәбәрне «Новая Кама» газетасында бастырып чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб - адрес буенча http://городелабуга.рф/ урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов